**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ СӘФӘР АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

423748, Иске Сэфэр авылы,
М.Вахитов ур., 16 нчы йорт.
Тел.5-60-43

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА СОВЕТА
СТАРОСАФАРОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423748, село Старое Сафарово,
ул. М.Вахитова ,дом 16 , Тел. 3-44-55

КАРАР
«08» ноябрь 2024 ел

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
№ 1

Актаныш муниципаль районы Иске Сәфәр авыл җирлегенең Иске Сәфәр, Иске Кадермәт, Терпеле торак пунктларында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Актаныш муниципаль районының «Иске Сәфәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 25.1 статьясы нигезендә, Иске Сәфәр авыл җирлеге башлыгы КАРАР БИРӘ:

1.2024 елның 18 ноябренә Актаныш муниципаль районының Иске Сәфәр авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Яшәү урыны җирлек чикләрендә теркәлгән 18 яшькә җиткән һәр гражданнан, Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация кысаларында мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, Украинада махсус хәрби операция зонасында контракт буенча хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләр, хәрби хәрәкәтләр ветераннары, 1 төркем инвалидлары һәм көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, аларның саны җирлектә яшәүчеләрнең гомуми санының 30 процентыннан артмаска тиеш, һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп 2025 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым түләүне кертүгә ризамы:

**Җирлек торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;**

**Җирлек чикләрендә халыкны электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру;**

**Җирлек территориясендә төзекләндерүне оештыру;**

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Иске Сәфәр авылы, М.Вахитов ур., 16 йорт.

4. Актаныш муниципаль районының Иске Сәфәр авыл җирлеге башкарма комитетын халык җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Иске Сәфәр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында халыкка җиткерергә.

6. Үтәлешне контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Иске Сәфәр авыл җирлеге
Башлыгы А.К.Гиздуллин